Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт
авыл җирлеге советы
423066 **ЯңаКармәт** авылы
Муса Җәлил урамы,15а нче йорт
тел. 4-92-33 факс

Муса Җәлил урамы, 15а нче йорт
Яңа Кармәт авылы , 4203066

Совет Новокиреметского сельского
поселения Аксубаевского муниципального
района
42306 с.Новая Киреметь
улица Мусы Джалиля, д.15а
тел. 4-92-33 факс

ул. Мусы Джалиля, д 15а,
с.Новая Киреметь, 423066

Тел. (8-84344-4-92-33) ОГРН 1021605359709,
ОКПО 04311599, ИНН/КПП 1603001197/160301001
E-mail: *Nkir.Aks@tatar.ru*

# Карар

№7 2022 елның 9нче ноябре

«Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлегенең Индустриаль бистэсендә гражданнар җыены үткәрү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елның № 131 - ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының “Яңа Кармәт авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында” 2019 елның 5 ноябрендәге 98 номерлы карарына таянып.

Карар итте:

1. 2022 елның 21 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлегенең Индустриаль бистәсендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2023 елда Аксубай муниципаль районының Яңа Кармәт авыл җирлеге Индустриаль бистәсе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булмаган һәр кешедән, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, хәрби хезмәткә мобилизацияләнгән һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 2000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә килешәсезме

1) Авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен контрольдә тоту, әлеге кагыйдәләргә туры китереп, җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру.

- Индустриаль бистәсе территориясендә үсемлекләрне чабуга килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү
2) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- кышкы вакытта Индустриаль бистәсе эчендәге юлларны карап тоту, урамнарны кардан чистарту килешүе буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү.
- Индустриальбистәсе урамнарында вак таш түшәлгән юллар төзелеше (сатып алу, ташу, җәю, вак таш, туфракны тигезләү, ком һәм грунттан нигез салу, шартнамә буенча эш өчен түләү)

"ӘЙЕ" " ЮК" "ТЫЕЛЫП КАЛДЫ"

4 Җыенны үткәрү урыны - Индустриаль бистәсе мәчете, ТР, Аксубай районы, Индустриаль бичтэсе, Индустриаль ур., 21а
5. Җыенны оештыру һәм үткәрү өчен җаваплылыкны Яңа Кармәт авыл җирлеге башкарма комитетына йөкләргә.
6. Әлеге карарны Яңа Кармәт авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча бастырырга: http://aksubaevo.tatar.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә
7. Әлеге карар кабул ителгән көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районының
Яңа Кармәт авыл җирлеге башлыгы И. Р. Шакиров